**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре №5

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Шегер авыл җирлегенең Шөгер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, күпбалалы гаиләләрдән (дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалар), тыл хезмәтчәннәреннән һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, МХОда катнашучыларның гаиләләре, тыл хезмәтчәннәре, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Шөгер авылында Октябрь тыкрыгы, Завод, Ибраһимов, Киров, Ленин, Герцен, Тукай, Җәлил, Сәйдәшев, Гагарин, Гафиятуллин, Такташ, Почта, К. Маркс, Горький, Больничная, Павленко, Садовая, Пушкин, Халиков, Коммуна, зубай бистәләре, Габбасов тыкрыгы урамнары буенча юлларны кардан чистарту; Шөгер авылының Завод, Пушкин, Павленко урамнарындагы юлларның чокырларын вак таш белән ремонтлау);

2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Шөгер авылында Завод, Ибраһимов, Киров, Ленин, Герцен, Тукай, Җәлил, Сәйдәшев, Гагарин, Гафиятуллин, Такташ, Почта, Маркс, Горький, Больничная, Павленко, Садовая, Пушкин, Халиков, Коммуна, Зөбәй, Габбасов тыкрыгы, Октябрь тыкрыгы урамнары буенча урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, );

3) урамнарны яктырту җайланмасы (Маркс урамында урамнарны яктыртуның яңа линиясен урнаштыру);

4) торак пункт территориясен төзекләндерү (берьеллык чәчәкләр сатып алу; Габбасов тыкрыгында авария хәлендәге агачларны кисү; Ленин урамында, стадионда һәм «Яшьлек» авыл паркында үләннәр чабу);

5) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Маркс урамындагы җәяүлеләр күперен ремонтлау);

6) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу);

7) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Шөгер авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров урамы, 17 нче йорт административ бинада, Киров урамы, 23 нче йорт, «ЛТС» ҖЧҖ-Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, 32 нче йорт, Ленин урамындагы Шөгер СДК, 35 нче йорт, Горький урамындагы Шөгер участок хастаханәсе, 4 нче йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

Р.Н.Гафиятуллин